**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ**
**КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** КАРАР

10 март 2023 ел **Чирмешән авылы** №61

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 07 июнендәге 233 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 07 июнендәге 233 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктны бәян итәргә: «Үз эшчәнлегендә сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет Россия Федерациясе Конституциясе, Федераль конституцион законнар, федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм боерыклары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) указлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары һәм боерыклары, муниципаль хокукый актлар, шулай ук әлеге нигезләмә белән җитәкчелек итә».

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе Җамалетдинов И.М.